**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында**

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы итеп үзгәртеп корырга, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсе, ә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен тапшырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен башкару белән бәйле йөкләмәләр өлешендә, шул исәптән төзелгән килешүләр һәм шартнамәләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр буенча да, хокукый дәвамчысы булып тора;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен башкару, шул исәптән төзелгән килешүләр һәм шартнамәләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр буенча да, хокукый дәвамчысы булып тора.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указ нигезендә үзгәртеп кору чараларын уздыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы турындагы нигезләмәләрне, әлеге

министрлыкларның структурасын һәм хезмәткәрләренең чик санын эшләргә һәм расларга, шулай ук «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча кысаларында аларның эшчәнлеген финанслауга ассигнованиеләр күләмен билгеләргә;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары санын билгеләү турында тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм башка хезмәткәрләргә, алар әлеге Указда каралган үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә эштән азат ителгән очракта, законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 2 августындагы ПУ-662 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы, 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1168 номерлы һәм 2018 елның 14 июнендәге ПУ-426 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасының II бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләрен өстәргә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-900 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 ноябрендәге ПУ-1122 номерлы, 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 29 августындагы ПУ-773 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы һәм 2018 елның 20 февралендәге ПУ-187 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керә торган вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы спорт министры»;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа егерме дүртенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры»;

в) егерме дүртенче – утыз бишенче абзацларны тиешенчә егерме бишенче – утыз алтынчы абзацлар дип санарга.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 22 июнь
№ ПУ-454